# Яшен.

(Якташларым – Идел буе егетләренең ком иле Төркмәнстан якларындагы хезмәтенә багышлана)

Нindидер кайгы, моң сөйләп сап-сары чүл иңрәп ята. Барханнар үлек чыккан өй кебек. Гүя, гомергә терелмәскә җан сызланып, күңел кайтаргыч шәрәлек-бушлык белән катып калганнар...

“Онытылган каберлек…үлгән җир. Бу зираттан адәм балалары түгел шайтан үзе җәяүләп качар! Ата-баба хезмәт итмәгән монда. Шундый җирдә хезмәт итәм дип илгә язсаң, дөнья бетереп көләрләр. Кайларда гына йөрми бәндә баласы!”

Эх, кайнаган җирдә кайнап яшәргә насыйп булмады, алгы сызыкта хезмәт итәргә язмагандыр инде... Хыяллар, планнарның җилгә очуы шушы буладыр, күрәсең?! Үлгән җирдә - үле хезмәт. Борчылды, көрсенде Салих тулы хокуклы солдат булып яши башлавының беренче атнасында, миллионнарның күзләре ышаныч, өмет белән текәлгән җаваплы хезмәт постындагы солдатларның бәхетеннән көнләде ул. Халкының, тынычлык сөйгән дөньяның бәхете, матур тормышы өчен җаваплы көрәшче була алмадым – бәхетсез мин, дип уйлады.

Колач җәеп үскән Иделен, чәчәкле-сандугачлы тугайларын, тургай җырына күмелеп дулкынланган иген басуларын, гүзәл балачакның суынмас эзләре калган чикләвекле тау буйларын юксынып уйлаганда: “Ышанычыңа лаек була алмады улың, Иделем!” – дип яна иде яшь солдат.

“Стариклар” дип йөртелгән частьнең күптәнге солдатлары “шомарту мәктәбе” дип исемләнгән “Яшь көрәшчеләр курсы”н үткәндә бригада замполиты сөйләгән сүзләр әле дә колагы төбендә чыңлый Салихның, тик бу сүзләрнең үз хезмәтендә чагылышын күрә алмый интегә ул. Часть замполиты ялкынланып , гадәттәгечә көр-чиста тавышы белән сөйләп киткән иде:

“Егерме ел буена алгы рәтләрдә, учениеләрдә “отлично”, “яхшы” билгеләре белән танылган зенитно-ракетный бригадага хезмәткә килүегез белән котлыйм сезне, яшь солдатлар! Кояш яктысы, күк аязлыгы, халкыбыз – Ватаныбызның беренче сызыктагы сакчылары сез! Бу – данлы хезмәт! Хөрмәткә лаек хезмәт урыныгыз белән горурлана аласыз!..”

Бу сүзләрдән соң зал буйлап таралган көчле дулкын тәэсирендә кубарылып, озак кул чабулар Салихның күз алдыннан мәңге китмәс!

“Шуны яхшы белегез, яшь лачыннар,-дип дәвам иткән иде полковник,- алдынгы сызык – алдынгы тәртип, беренчел дисциплина , төгәллек һәм үз-үзеңә ныклы ышанычта булу дигән сүз. “Бер кеше бөтенесе өчен, бөтен кеше бер кеше өчен” – бу безнең хезмәт нигезе, бу – безнең тормыш, безнең һәр минуттагы сулышыбыз! Ә беләсезме, бу ничек аңлатыла?”

Ул мисал китерде: “Әйтик, радиотехниклар “цельне” тота алмадылар, моның өчен бары тик кабинадагы солдат кына гаепле булсын ди – канатлы дошманга безнең тылга үтәргә “коридор” ачыла һәм бөтен калган коллективның тырышлыгы юкка чыга – ноль булып кала; шуның белән бөтен бригада ның юкка чыгуы һичшиксез! Ә күпме халык, күпме төзелеш, гөлләр

үскән җирләр көлгә әйләнергә мөмкин... Барысы да бары тик бер солдатның гаебеннән... Хәер, сез үзегез үк күрерсез тиздән безнең хезмәтнең никадәрле җаваплы икәнлеген!
Ил-халык ышанычына лаек булыгыз,солдатлар! Безнең коллектив хезмәт канатлы дошман өчен һәрвакыттагыча үлем белән янасын! Ил күгендәге якты кояшны кара болытлар капламасын! Меңнәр, миллионнар көрәшендә туган гүзәллекне дәһшәтле яшен сукмасын – бөтенебез бер булып корыч сафка басыйк!"
Әйе, бу сүзләрне ничек онытсын Салих. Шушы минуттан башлап ул радиотехник булам дип үз-үзенә сүз биргән иде. Частьнең танылган солдатлары да радиотехникларның хезмәтен иң җаваплы, иң авыры диләр; димәк, планнар җимерелгән икән, бәхет дигәне Каф тау артына качмаган, радиотехника һөнәренә укы да, иң беренче хезмәт постына бас – бу инде бәхет кояшы тоттым да дигән сүз...
Шундый фикер береккән иде солдатыбызда. Ләкин аның чын хезмәте бөтенләй башкача башланды. Курстан соң яшь солдатларны подразделениеләргә бүлү башланганда Салих рота командирына хәл иткән теләген белдергән иде, ул командирның ике куллап риза булырына ышанды, тик, бөтенләй көтелмәгән җавап ишетте:

- Сезнең гражданкада ике еллык шофер стажы бар, ә бу безнең өчен күп нәрсә сөйли. Сезне автомобильный ротага инде күптән беркеттек, сез анда штаб начальнигын йөртәчәксез.

Ул чакта яшь солдат үз эчендә нидер сынган кебек тойды, кинәт хәтере калып әйткән иде:

- Шофер ул профессия, миңа беренче сызык, җаваплы хезмәт посты кирәк, теләгемә каршы килмәсәгез иде, иптәш капитан?!

Алар озак кына сөйләштеләр ул чакта, капитан яшь солдатка билгеләнгән хезмәт постының никадәр җаваплы, алыштыргысыз, мөһим икәнлеген аңлатырга тырышса да, "инде тотам дигәндә тагын качты бәхет кошы" дип күңелсезләнгән иде Салих. "Хәерчегә җил каршы" дип әллә кайчангы бабайлар әйтемен дә телгә алып куйган иде ул.
Менә бер атна була инде, ул штаб начальнигын йөртә. Подполковник аңа беренче көннән үк ошады- аз сүзле, киң күңелле һәм бик төгәл кеше булуы беләнме, таләпчән һәм үтә дә игътибарлылыгымы Салихны үзенә тартты, яшь солдат начальнигына хөрмәт белән карый. Мактарга бик ярата торган кеше булмаса да, подполковник чиста, ялтырап торган машинага утырган саен "яхшы, шулай кирәк тә" дип куя иде.
Бөтенесе яхшы булса да , күңеле-йөрәге белән үз хезмәтеннән риза түгел иде Салих. Әнә бергә чакырылган иптәшләре: "Җиңел түгел...,- дип куялар,- сиңа рәхәт, син бәхетле!- дип аның эшеннән көнләшәләр, карашларында хөрмәтләү, олылау күренә. "Эчтәгене белмиләр шул, ир сүзе суган түгел, базарга чыгарып сатып булмый. Миңа соң җиңеле кирәк идемени хезмәтнең?!" Егетнең уйлары шулай тынгысыз кала бирде.

Кичә начальнигы Ташкетка киткән иде, менә бүген отбойдан соң ул подполковникны каршы алырга вокзалга килде. Квартирасына кереп киткәндә аерым игътибар белән әйткән иде ул:

- Бүген җаваплы "яшен" булуы ихтимал, булса – 5 минутта син монда килеп җитәргә тиеш, кара аны, ут бул!

Аптырады Салих , я, ничек башка сыйдырмак кирәк. Шундый ап-аяз йолдызлы төндә яшен кайдан булсын ди ул?! Кайтып койкасына яткач та үз алдына көлеп куйды: "Аяз төндә - яшен... бигрәк әкәмәт кеше инде бу начальнигы."

Одеялы астына керү белән бервакытта да тыныч кына йоклап китә алмый ул. Маңгай күзең йомудан ни файда күңел күзең йокысыз булгач: ул татлы уйларга бирелеп Иделенә кайтып китә. Менә алар икәүдән-икәү генә Идел ярындагы чиста эре комда кояшка карап чалкан яталар... Янында күңел кояшың булганда ни кирәк тагын дөньяда?!Идел дә бары тик алар өчен генә шаулый, кояш та бары тик алар өчен генә миһербанлы карый, яр читендәге таллар да алар өчен генә, бөтен дөньясы аларныкы...

" –Син кайчан кайтырсың, Салих?

-Әле китмәдем дә бит, Ләйсән...

-Ике ел бик озак гомер бит... синсез...

-Ике ел ир-ат өчен тик сынау гына ул!"

Татлы уйлар төшенә бәйләнеп китә аның. Ничек йоклап киткәнен дә сизми кала Салих. Менә алар Идел кочагында су коеналар, Ләйсәне ап-ак балык төсле... ул аның каршына йөзеп килә... Идел дулкыннары аша йөрәкнең әллә кай аулак почмакларына кадәр татлы дулкыннар йөгереп үтә... И-и-и, бу кыз кешенең, кармакка суалчан да кигерә белми бит: Салих, кызны булдыксызлыкта йомшак кына гаепләп, суалчан кигезгән кармакны аңа бирә... шул вакыт әллә кайдан – Иделнең төбеннән килгән кебек күкрәү авазы колакка чагылып үтә, ул да булмый горизонтта кара болытлар куерып чыга, күктә яшен камчылары уйный башлый, бөтен Идел буен калтыратып күк күкри...

Ләйсән егетнең кулларыннан тарткалый:

-Әйдә, Салих, качыйк тизрәк!

-Курыкма,- ди Салих,- Яшен куркынычмыни ул, тоз түгел – яңгырда эремәбез!

-Әйдә инде, киребеткән,- дип чәбәләнә кыз, балаларча үпкә катыш һәм егетнең кулларыннан көчле итеп тарткалый башлый. Салих күзләрен ачып җибәрә, "ах, төш кенә икән", күрше караваттагы карт солдат аның одеялын тарткалый.

-Уяндыңмы? Әйдә, киен тизрәк. Әнә, дневальныйга телефон аша команда бирәләр. "Яшен" булачак.

Салихның фикерендә начальнигы кичен кисәтеп куйган сүзләр кабатланды. "Яшен!"

Ул инде коридорга чыкканда бөтен казарма эче лампочкалар яктысында балкыды һәм көчле күкрәү кебек дневальныйның командасы яңгырады:

-Подъ-ем! Яшен!

Салих йөгереп киткәндә әле генә тынычлап-тәмләп йоклаган казарма тынгысызланган умарта оясы кебек гөҗләп калды.
Өч минут тулар-тулмас ул инде үзенең җиңел машинасы белән выжылдап офицерлар йортына килеп туктады. Подполковник һәм башка күп офицерларның инде аяк өстендә булып, түземсезләнеп үз машиналарын көтеп торуына гаҗәпләнде ул. “Ут юкта төтен булмый, ләкин кая соң уты, нәрсә булган икән?”

Штаб начальнигы утырып та җитмәстән командалар бирә башлады:

- КПгә! Газ-поликка кадәр! Безнең өчен 15 минут!

Инде ничәмә-ничә тапкыр үткән “командный пункт”ка илтәсе юлны Салих күзен бәйләсәләр дә табар, һәр сикертмәсенә тиешле хәрәкәтләр ясап үтәр – ул аны яттан белә иде.
Машина үкереп КПга оча, подполковник гадәттәгечә киерелеп утырмаган, ул, гүя, машинаны узып йөгерергә тели; алга сөрлеккәндәй , күзләрендә ялкын, йөзе җитди – аның һәр хәрәкәте ниндидер зур, җаваплы көрәшкә ташланырга торган кыю сугышчыны хәтерләтә... Ниндидер олы эш – кичектерелмәс ашыгыч эшне тоеп, күрәсең, яшь солдатның йөрәге моторына кушылып эшли, соңгы егәрлеге белән ыргылган машина тизлегенә яшь солдатның да йөрәк ялкыны кушылды кебек... КПгә җитәрәк подполковник фараларны сүндерергә приказ бирде...
...КП дип аталган, цементланып эшләнгән бөек тауга килеп җитүгә подполковник җәһәт кенә сәгатенә күз салып “отлично” дип куйды һәм тауга күтәрелгән баскычтан югарыга менеп йөгерде. Хәрби телдә идарә һәм боевой приказлар бирелгәнен белә Салих, тикмәгә генә карт солдатлар аны коммунистлар партиясе дип йөртмиләр шул!
Минут та үтмәде, җиңел машиналар, автобуслар КП алдына килеп туктадылар: офицерлар, ут капкандай, штаб начальнигы күтәрелгән баскычка ташландылар...
“Ниндидер җитди эш. “Яшен” дә ниндидер сер бар, тик нинди сер соң?” Яшь солдатның күңеле бер минут та тынгылык тапмады, ни булганын тизрәк беләсе килде аның.
Ул инде 10 минут көтә әнә үз начальнигын, тауга мену баскычын дүрт күзләп күзәтә, ләкин, анда бер генә кеше дә күренми, тик нидер эзләп тау башында радиолокаторлар гына әйләнеп утыралар.
Салихның түзәр змәле калмады, ул, инде икенче елын хезмәт иткән автобус шоферы янына атлады. Яшьләр белән бик иркенләп, тиң күреп сөйләшергә, киңәшләре белән ярдәм итәргә яратучы бу рус егете белән Салих арасында беренче көннәрдән үк яхшы мөнәсәбәт урнашкан иде.

- Петя,- дип сүз башлады ул солдатның янына кереп утырып,- кайчан бетәр икән бу “Яшен” дигәне?
- Төрлечә була,- дип бик иркенләп сөйләшергә ризалыгын белдерде ул,- “цепьләр” егермеләп-утызлап булса ике, ике ярым сәгать, ә иллегә җитсә өч сәгатьтән дә артып китә. Кем белә, бүгенгесе, бәлки, учебный да түгелдер...

Егетнең шулай якын дус күреп иркенләп сүз башлавы Салихны җилкетеп куйды, ул инде тартынмыйча сорады:

- Петя, нәрсә соң ул “Яшен”, сөйлә әле, зинһар!?
- Вот әкәмәт!-дип елмаеп куйды рус егете, - бөтенебездән алдан килеп җитте үзе, ә үзенең нинди олы эшкә катнашуын да белми . Я, тыңла алайса. “Яшен” – ул повышенная боевая готовность! Ул я учебный, я дошман чикне бозганда бирелә. Менә хәзер күктә кайнар сугыш бара, тик , учебный булырга тиеш. Җаваплы солдатлар, офицерлар экраннар аша, аппаратлар артында – һәркем үз постында. “Цель”ләрне табалар. Тотып алалар, таныйлар һәм юк итәләр. Часть командиры һәм штаб начальнигы бу сугыш белән командалык итәләр, чүлләрдәге боевой точкаларга приказлар бирелә: әгә дә, чыннан да, дошман чикне бозган булса, безнең ракеталар телгә килә. Менә шулай дәһшәтле Яшенгә каршы көрәш бара, берсүзсез без Яшенне булдырмый калабыз, чөнки менә син үзең дә Яшеннән алда монда килеп җиттең... Э-э-э, брат, белергә кирәк, бу кухняда пластинка әйләндерү генә түгел инде!

Нәкъ менә шушы минутта яшь солдат йөрәгендә нидер күкрәде, күңелендә яшен кебек бер нәрсә ялтырады, горурлык һәм чиксез сөенеч күзләрендә якты нурлар булып кабынды!

Ике сәгатьтән артык вакыт үткәч тау баскычында офицерлар күренде. әнә алар кызып-кызып сөйләшәләр, бәхетле елмаялар, адымнары салмак, горур.

Штаб начальнигы да Салих янына килде, аны алыштырып куйганнар диярсең: шат, көләч, сөенеч-бәхет бөркеп мөлаем караган акыллы күзләре җиңү тантанасын сөйли.

Күмәк шатлык яшь солдат йөрәген дә үз ирегенә ала, бәхетле дулкыннар белән тутыра, Салих та иркенләп елмая.

- Барысы да отлично! Җиңү! Молодец, сынок! Иртәгә сутка увольнение сиңа! - дип Салихның җилкәсеннән кага подполковник; әйтерсең, бер Салих кына бөтен җиңүдәге төп роль, әйтерсең, тиңсез шатлыкның беренчел сәбәпчесе ул гына...Машинага штаб начальнигы белән рәттән штурман дип йөртелгән майор да утырды.
- Утыз ике «цель», утыз ике - әйтү генә җиңел!- дип сүз башлый подполковник.
- Нинди радиопомехлар, нинди үткен маневрлар – тик барыбер җиңү безнеке! – дип елмая майор-штурман.
- Әйе, “Яшен”нән алда яшьни алдык!

Подполковник Салихка дәшә

- Ә ничек син часть командиры шоферыннан алда өлгерә алдың?

Шулай булды инде...,- дип, эчке шатлыгын яшерергә тырыша яшь солдат.

Машина салмак кына тирбәлеп částька кайтып килә. Яшь солдатның йөрәк дулкыннары ритмына тирбәлә ул. Салих ян тәрәзәдән тирә-якка күз сала. Гаҗәп, кайгылы сары чүлләр кызарып-алсуланып килә кебек, гүя аларга кемдер җан өрә. Саксауллар да төзәеп басканнар, баксаң. Аларда да үзләренә

генә хас яшеллек бар икән. Биектә-биектә исемнәрен колак ишетмәгән кошлар җыр сузалар түгелме?! Әйе! Күр син, чүл йөзендә кечкенә, гүзәл чәчәкләр дә балкый, ләбаса!
Ю-юк! Ничек кенә “үлгән җир” булсын, кайнап торган тынгысыз җанлы җир бит бу! Һәр минут олы тормыш өчен көрәш кайнарлыгы белән яшәгән җир үле буламыни?!
Туган Иделе буйларында үскән гөлләрнең гүзәллеге дә менә шушы чүлләр дөньсындагы кайнар тормышка бәйледер. Якты кояшның назлы нурларында бу җирләрдәге олы тормышның чагылышы бардыр?!.
Идел егете – яшь солдат Салихның йөрәгендә уйнаган бәхет яшене, якты елмаю булып горур, нурлы карашында чагыла.

29 апрель 1969 ел. Чарджоу.

## Беренче аңлашу.

Табигать шулай яраткандыр аналарны – һәрвакыт тынгысыз, гаять кызыксынучан, үтә сизгер күңелле булуларында кем генә алыштыра аларны?!
Инде сөю дигән нечкә нәрсәгә дә катнашмасалар соң... бу мәсьәләдә күңелнең тупас булуын ничек танымыйлар үзләре. Ун ел бергә укыдыгыз, армиядән өч ел көтеп алдың, аннан соң менә икенче ел бит инде. Күпме көтәргә була тагын, янәсе. Канатлар чыккан кошның очып китүе хәерле,имеш. Әй, бу аналарның кысылмаган җирләре дә юк шул.
Картлык көнебездә төпчек кызыбызның туйларын да күрергә язмас микәнни, дип болай да кайнаган йөрәгенә ут өстәмәсәләр соң. Әй, ул да инде, дип егетен эченнән сүкте кыз,- очраштыкмы – авызына су каба да тора.
Чыннан да, кыюсыз шул... Очрашкан саен бер үк күренеш: исәнләшү-күрешү, җыен юк-барны сөйләшү дә.
-Сау бул, тыныч йокы.
-Хуш. Тәмле төшләр сиңа!
Юк! Болай дәвам итәргә тиеш түгел. Ике күзен дүрт итеп үзем әйтермен әле... Бу юлы кыз менә шундый береккән фикер белән очрашу урынына ашыкты.
... Аяз күктә йолдызлар күз кысышып шаян елмаеша, тулы ай шыпырт кына гашыйкларның сүзләрен тыңлый:

- Беләсеңме нәрсә...беләсеңме,- кыз урталай янган йөзен егеткә борды.

  Озын керфекләре йөрәгендә тибрәлгән дулкыннар тәэсирендә бер күтәрелә, бер төшә, нигәдер дымланып калган, әле моңаеп, әле яктырып киткән күзләреннән егет кызның күңелдәгесен укыды.

Мин бәхетле, дип уйлады егет. Кыз егетнең үзенә йотылып караган күз карашыннан уңайсызланып башын аска иде. Бер генә аваз да чыгарарга курка ул, авызын ачу белән йөрәк түрендәге сүзе ычкынып китәр кебек тоя.

- Әй лә, сиңа сөйләсәң ни дә, сөйләмәсәң ни. Син аңлый торган кешеме?! Бу сабыйдай беркатлы сүзләрдә нидер яшеренгәнен тойды егет.
- Я, әйт инде. Ә мин сине аңларга тырышырмын.

Егетнең гөнаһсыз, йомшак, гадәти булмаган үтенечле тавышы кыз күңелен эретеп җибәрде. Әйтергә дип уйлап килгән сүзләр дә әллә ничек эреде дә югалды. Алар онытылган айга төбәлделәр, гүя, бер-берсенә әйтергә теләгән сүзләр айга язылган... Кыз шулчак кабат җанланып китте, нидер исенә төште, ахры, әллә ай нидер пышылдады:

- Беләсеңме, без болай йөри алмыйбыз!

Әйе, дип чак кычкырмады егет, елмаюда балкып.

Менә юләр, дип уйлады кыз. Мин аның тынычлыгын алып аптыраштa калдырырга телим, ә ул сөенечен эченә сыйдыра алмыйча рәхәтләнеп елмая. Әллә, әллә ул болай гына йөриме? Бәлки хәзер яратмый башлагандыр?

- Юләр син!- диде кыз. Аның күкрәк тавышыннан ,минем юләрем син, дигән иркәләүне тойды егет.
- Әйе, синең алда һәрчак юләр мин, әллә шуны яңа гына беләсең?!

Егет күңеле инде җырлый иде.

- Бик беләсең килсә, әйтим инде – син, син, ...әнә теге ай кебек, һәрвакыт ...салкын...янмыйсың да...яндыр...”.

Нечкә хисләр белән һаман нечкәреп килгән эчке бер каушаудан, калтырап туган өзек-өзек авазлар бөтенләй өзелеп калдылар. Кызның иңбашларын егетнең көчле куллары гүя пешереп алды, ул акылга буйсынмас хәрәкәтләр белән егет кочагына тартылды, дәртле-кайнар иреннәр бер-берсен эзләп тапты. Кызның җиңелчә генә башы әйләнеп китте. Тыеп булмаслык калтырау белән йомшарып калган буыннарга татлы бер рәхәтлек таралды, гәүдәсен бер сәер йомшау басты.

Кыз үзен бөтенләй җиңел сизде, әйтерсең ул каз мамыгыннан да җиңел хәзер, чак кына җил иссә дә очып китәр менә. Егет кочагында гүя эреп бара ул, иреннәр аңлашылмас сүзләр пышылдаша, ә йөрәкләр...йөрәкләр үз телләрендә аңлашалар, ачыктан-ачык сөйләшәләр.

Ай исә шаян елмаеп , я, я, җитәр сезгә, бигрәк тә күп сөйләшеп ташладыгыз тагын, дип гашыйкларга бармак яный иде.

Март 1969 ел. Чарджау.

## Таң атканда.

Чишмә буендагы яшел-хәтфә чирәмнәргә эленгән иртәнге чыклар таң атканда зөбәрҗәт бөртекләредәй җемелдәшә,талгын гына искән таң җилләре тәмләп йоклаган гөлләрне иркәләп уята, бәхетле елмаюлары белән гөлләр таң кояшын сәламлиләр. Юкә агачының йомшак яфраклары ышыгында төнлә

черем итеп алган сандугачлар дөньяга җан өреп туып килүче алсу таңга данмактау җыры башлап җибәрделәр.

Егет белән кыз ап-актан киенгән каен сылуы ышыгында янәшә генә чалкан яталар.

Аһ, нинди рәхәт җәй таңын каршылавы! Бигрәк тә күңел күгәрченең янында булса.

Тик ул “кош” бу кадәр телсез булмасын иде... Шулай уйлады кыз һәм яфраклар арасыннан сызылып үткән кояш нурларында йомылырга җитеп кысылган күзләре киң ачылып, ялкынланып китте: ул оялып, тыелып кына елмайды да егеткә дәште:

- Кара әле дим, әнә теге баш очындагы ботакка кара әле.

Егет күзләре белән кыз ишарәләгән ботакны эзләде һәм кинәт шаркылдап көлеп җибәрде.

- Аһ, әдәпсезләр! Тапканнар... кеше баш очында... узынмасагыз, әзрәк оят дигән нәрсәне онытмасагыз соң.

Баш очларында гына сандугач кызы белән сандугач егете дөньяларын онытып, чүкелдәшә-чүкелдәшә кайнар хисләрен бүлешү эшендә иделәр.Әйтерсең, алар дөньяда бер үзләре генә.

Кыз, урлау өстендә тотылган кешедәй, кызарынды. Күзләрен егеттән яшерергә теләп торып утырды да, оялып-уңайсызланып башын аска иде. Авыр хәленнән котылу юлын эзләп ул сүзне икенчегә борырга теләде, ахры.

- Я, куй әле шуларны! Яшермичә әйт әле, син хәзер нәрсә хакында уйлыйсың?

Егет мыек астыннан елмаеп кына җавап бирде:

- Син нәрсә турында уйласаң мин дә шул турыда
- Әй, оятсыз! – кыз сикереп торды да күлмәк итәкләрен җилфердәтеп йөгереп китте – куып җит!

Аның чиста чишмә кебек көмеш-саф тавышыннан сандугачлар да айнып китте, әнә алар кызы артыннан җан-фәрман йөгергән егетне үртәп торалар, чүт-чүт, юк синнән егет, юк-ю-у-ук. Үзалдына , сезнең аркада гына , оятсызлар, дип кабатлый иде егет.

25 март 1969 ел. Чарджоу.

## Чәчәк атканда.

“Буй җиттең, үз-үзеңә хуҗа була бел! Өйдә үзеңне ялгыз сизмә – синең белән өй бәхете дә кала. Кара аны, урам як тәрәзәгә ялан саен күз салма! Аң бул, тәрәзәдән күзен алмаган кызның бәхетен үтеп-сүтеп йөрүчеләр урлый, диләр. Бәхетең ияреп китмәсен!” Ата-ана бердәнбер кызларына шушы киңәшләрне биреп кунакка китеп бардылар.

Һай, нинди иркен , сулышларга кадәр киңәя, бигрәк тә рәхәт икән үз-үзеңә хуҗа булганда, һәр адымыңны алай кирәми, болай килешми дип такылдап “җан итен кимереп торучылар” булмагач тормыш никадәр матур, ләззәтле икән! Кыз шулай уйлады, иңнәреннән авыр йөк төшкәндәй, үзенең җиңеләеп калганын тойды. Көлке түгел шул, егерме яшькә җитеп тә ата-ана

рамкасында интегеп яшәве, ул бит җансыз картинка түгел, яшьлек рамкаларга сыеша аламыни ул?

...Таныш сызгыру...әллә ул кайтамы? Кыз тәрәзәгә ташланды һәм тәрәзә каршында гүя нигәдерябышып калды ул. Кояшка чыгарга чәбәләнеп ятучы тәрәзә белән бүленгән күбәләктәй, кулларын болгый-болгый һаман тәрәзәгә йотыла бара, әйтерсең, аның 15 яшьлек чагы, әйтерсең, ул әле сигезенче класс җилбәзәге генә, гүя, ул авыл хуҗалыгы техникумын да бетермәгән, колхозында агроном булып та эшләми: аның бөтен кыланышлары самими беркатлылык, балалык бөркеп тора иде...

“Ул! Чыннан да ул бит!”

Кыз ул егеттән өч класска түбән укыды, ләкин бу яшь аермасы аларның ныклы-ялкынлы дуслыгына бер дә зыян итә алмады. Егет унынчыны бетереп авыл хуҗалыгы институтына укырга киткәндә кызга әле 15 яшь кенә иде. Ул 8нче класста гына укый иде. Менә егет диплом яклап туганякларына агроном булып эшләргә кайтып та килә. Баладай җилкенеп кыз егет каршына йөгереп тә чыкты.

- Исәнмесез!
- Сезнең хәер-догада, - дип һәрвакыттагыча шаяртып, көлкеле итеп җавап бирергә ашыкты егет һәм акыллы күзләрен кыса төшеп, балаларча аптыраган кыяфәттә:
- Әтекәй генәм, кем кызы була бу? Менә сиңа мә, бишектә генә идең түгелме соң, кайчан тәпи басарга өлгердең, кечкенәм?!

Авыл урамында көмеш сафлык сибеп пар көлү яңгырап үтте. Бер-берләренә әйтеләсе олы, йөрәк сүзләрен һаман эчкәрәк яшереп әйтелгән вак-төяк сүзләрдән соң кыз егетне өйгә чакырды:

- Әйдә,артист, урамны сәхнә итеп кеше көлдермә әле!..Өйдә ялгызым, әниләр кунакта, үземә генә күңелсез, артист булганда күңелсез булмас, шәт, әйдә, керик.
- Биш куллап ризамын, бик кунакчыл апа ахры үзең,- дип кызга иярде.

Башы-азагы булмас сүзләр белән чәен өлгерткәнче кояш та баеды, сый-хөрмәт тулы өстәл башында сайрашып утыра торгач төн уртасы да җитте...

...Аулак өйдә ут сүнде. Төнге караңгылык яшьләрне үз кочагына алды. Саксыз адымнарның бәласедер, күрәсең, нидер төшеп ватылды, ниндидер аңлашылмас пышылдашулар, төнге эңгердә эреп югала барган калтыраулы, ярым-йорты өзек авазлар...

Караңгының күзе юк шул.

Кыз инде тәрәзәгә карамый, урамнан үтүчеләрдә нинди эше бар аның хәзер. Бәхете ияреп китмәде, киресенчә, ияреп керде – менә ул үзе белән рәттән.

Ата-ана кунактан кайтып кергәндә өйгә йозак кына хуҗа иде инде. Кызларының бәхете ияреп китмәгән, тик кызлары гына бәхетенә ияреп киткәнен сөйләде күршеләре.

29 март 1969 . Чарджоу.

**Не смотри в окно.**

(новелла)

- Ты уже взрослая, сумей быть сама себе хозяйкой. Не чувствуй себя без нас в одиночестве: с тобой остается еще счастье дома...Только не глазей в окно, будь умницей! Старшие говорят, что у девушки, не отрывающей взгляд от окон, счастье разбирают прохожие – как бы не ушло твое счастье с ними!

Отец с матерью, дав такие наставления единственной дочери, уехали в гости в соседнюю деревню.

...Ах, как проосторно! Оказывается, такая благодать – быть хозяйкой самой себе, даже дыхание становится свободнее. Когда нет стоящих над душой твоей каждую минуту, на каждом шагу предупреждающих “так не надо, этак нельзя” – насколько приятнее, прекраснее становится свободнее эта жизнь!

Такими чувствами наполнилась душа девушки, которая, напевая , порхала из комнаты в комнату , подобно бабочке. Словно тяжелая ноша свалилась с ее плеч: кажется , вмахнешь сильнее и – полетишь...

Легко ли в двадцать лет жить в рамках , определенных отцом и матерью? Ведь не картинка же она , наконец: разве можно юность стеснять в рамках?

...Знакомый посвист.

- Не он ли вернулся?

Девушка кинулась к окну, как будто ее туда притянули. Она зарделась вся , прильнула к стеклу , словно бабочка , стремящаяся выпорхнуть на волю.

В эти минуты она перестала быть похожей на окончившего техникум человека , работающего агрономом в деревне. Взгляд ее излучал наивный восторг и детскую чистоту души.

- Он! И взаправду ОН!

Когда Он , окончив десятилетку , уезжал в сельхозинститут, девушка была восьмиклассницей. Но разница в возросте и годы не охладили пламень их дружбы. И вот Он, защитив диплом агронома, возвращается в родные края...

По-детски порывисто девушка выбежала к Нему навстречу.

- Здравствуйте!
- Вашими благословениями!

Он, как и прежде, взял шутливый тон и , прищурив умные глаза , пристально глядя на нее, продолжил с притворным удивлением:

- Батюшки мои, чья же эта дочь?! Вот тебе на: не в люльке ли ты еще оставалась, когда же успела на ножки встать да какие зори тебя вырастили!
- А ты состарился, пока учился!

По деревенской улице серебряной чистотой прозвенел их смех.

- Пожалуйста, не превращай улицу в сцену , артист! Пошли в дом.
- С моим удовольствием, гостеприимная тетушка!

Пока девушка готовила чай , перебрасываясь с гостем шутками без начала и конца, настал вечер. Пока они сидели за столом , отводя душу в разговорах, настала ночь.
Девушка вспомнила слова родителей: “В окно не смотри” – и улыбнулась в душе. Она теперь в окно не смотрит: какое ей дело до прохожих! Счастье ее не с прохожими ушло, а с Ним пришло. Счастье ее с ней рядом...

А.Зиннатуллин. (перевод А.Давлетшиной)

## Эт оясында көчле.

Үзебезнеке дип аталган хөрмәтле председательләре үз теләге белән артта калган колхозга китеп баргач, семья хуҗасын югалткан өйдәй, колхоз бөтенләй бушап калган кебек иде. Күңелләрдәге сөенечле яктылык сүнгән кебек, колхозчылар бик пошындылар, үз кешеләренең каядыр читкә китүенә йөрәкләре белән риза түгел иделәр.

Нишлисең, тир тамганны гына ярата торган кеше түгел шул, үзенең кайнар тире кешеләрнеке белән рәттән тамганда гына яктыра, тыныч яши ала торган бәндә түгел иде. “Колхозыбыз - сыйлы, бай семья. Ә мин шул сый-хөрмәтле өстәл башындагы мулла кебек, бик рәхмәт, бик рәхмәт, үзеңнеке – шөкер! Колхозына төкер, дип ята алмыйм,”- шулай сөйләнә иде ул. Диңгезгә чыккан корабка хәерле сәфәр теләүдән башка ни әйтәсең тагын.

Райком үз кешеләре урынына отставкага чыккан бер майорны тәкъдим итте. Райком булып райком, сезгә кулай кеше, оештыра, кеше белән эшли белә, биографиясе заманның алдынгы кешсе булуын сөйли, дип агитация үткәргәч, колхозчылар аны председатель итеп сайлап куйдылар.

Бу бикләнгән йорт кебек йомык, характерлы, төптән юан чыккан гөмбәдәй ... кеше беренче очрашуларда ук күпләрнең күңел өметләрен сүндергән иде.

Яңа рәис бер-ике көн мыштым гына күзәтеп, үткәннәренә кайтып яшәгән картлар кебек, беркемгә бер сүз дә дәшми йөрде дә, җир сөргән кешедәй уфылдап креслосына килеп утырды. Шушы утыруында зур бер мәгънә барын белдереп карашы белән правление хезмәткәрләрен сөзеп чыкты да, күзләрен түшәмгә төбәп, ниһаять, тел ачты:

- Менә шуннан башлыйбыз!

Ниндидер олы бер идея, көчле фикерләренең халыкка әйтер алдыннан уенда асылынып , тәэсир көчен исәпләп торган кешедәй эшлекле кыяфәттә озак бүленеп торды да, үз-үзенә тирән ышанычта сөйләп китте:

- Күрдем, сезнең халык таркау яши, тормышыгызда бер бөтен эш өчен яну юк. Җитәкчеләр белән үзләрен рәткә куеп сүз көрәштерү, аның сүзләрен һәркем үзенчә тикшереп үзенчә эшләргә өйрәнгән. Беркайда идеаль чисталык юк – заман койрыгында яшисез!!! Бу көннән башлап яңа тормыш, яңача тәртипләр башланачак. Яхшы беләм мин, мине өйрәтәсе калмаган инде – сезгә дилбегәне нык тота белүче җитмәгән, - ул алдында торган кәгазьне шытырдатып йомарлады. – Менә шулай

берләштерергә кирәк,- һәм йодрыгын югары күтәрде,- шулай булганда гына заманча яшәп була!

Кабат уфылдап креслосына чумды.

- Идарә шуннан башланачак!

Аны правление аңламады, штаб начальнигы булган , диләр, бераз арабызда яши башлагач, күзләре ачылыр, мең мәшәкатьле кайнаган колхоз тормышы бу канцелярия хуҗасын үзенә тартыр әле, дип уйладылар.

Тик бер ай үткәндә яңа рәис бөтен яктан да күрсәтеп өлгерде, халык теленә менеп җырларда исеме яңгырады:

Калада йорты, тормышы.
Колхозда – креслосы.
Һәр көн көт шул креслодан
Буш тиеннәр коеласын.
Гөл үсәргә таш матый дип
Нигә соң көенергә?!
Вакыт түгелме ул ташны
Кубарып чөерергә?!

Әйе, колхозчылар яңа рәискә бакчада үскән гөлләргә комачаулаучы таш дип кенә, авылга тик ләззәтләнергә – ялга килгән, китәсе кунак итеп кенә карадылар. Инде колхозның күмәк җыелышында урыныннан алуны һәркем уйлап йөрсә дә , күңелләрдә һаман, үзен –үзе белеп китсен иде, райком ышаныч белән  күрсәткән кешене куу райкомның дәрәҗәсен түбәнәйтү була, дигән уй йөрде.

Колхозның ат караучысы Әптери агай да инде менә күптән уйлап йөри, ничек соң шул түр иясенә безгә кирәк кеше түгеллеген аңлатырга?

Җае бөтенләй уйламаганда-көтмәгәндә килеп чыкты. Соңгы айларда сөт буенча план үтәлми башлагач председатель агайны районга чакырып пешекләп кайтардылар. Менә шушы көннән ул креслосыннан кубарылды, сөтчелек фермасына “переворот” ясарга дип чыгып китте. Ферма тирәсендә ап-аяз көн уртасында күзләре белән йолдызлар чутлап барган җирендә бушап калган силос базына төшеп китмәсенме кресло иясе. Силос базы авызыннан сыерларга азык ташучы атчы Әптери күреп алган да ни булганын аңлый алмый, боз төбендә чалкан ята иде характерлы рәисебез.

- Әттәгенәсе, хуҗа үзе дә килеп җиткән икән, - дип тел шартлатты Әптери ага, баз төбендәге председательне күреп. – Эх-ма, яхшы да булган инде, агай-эне. Инде бетте ул чокырда силос, яңасын ачтырырга кирәк дип күпме тукыдым шул ферма мөдиренә. Председательнең рөхсәте юк, имеш, шулай җиңел котылмакчы булган иде, менә үзегез килеп карарга булгансыз икән, иптәш начальник. Бик яхшы иткәнсез! Тик анда төшеп буялып йөрмәсәгез соң!.. Әллә безнең халыкка ышанмыйсыз инде?

Әптери агайның сүзләреннән дөрләп кабынган рәис баз төбеннән акыра башламасынмы:

- Не сметь миннән көләргә, деревенщина!!! Молчать! Төрмә ..., сукин сыннар! Юлыма аркылы килүегез генә җитмәгән, инде чокыр казып башымны бетерергә уйладыгызмы, антисоветщина! Тончыгып үлсен дип монда сасы нәрсә җәйдегезме? Мин сезне суд каршына бастырырмын, папуаслар!

Эчендәген бушатып ташлагач рәис тынып калды. Ә Әптери агай мыек астыннан гына елмаеп тора бирде. Тавыш хөрлеге, куркыту белән генә хәлдән чыгу юлын күрмәгәч, кресло иясе тавышын йомшартты:

- Я, кеше бул инде, Әптери ага, чыгар бу үләксә чокырыннан. Сабый булмыйк, бир кулыңны...
- Менә шулай иптәш начальник, без куркудан узган, сүз дигәне үзебезнеке. Эт оясында көчле икән. Безнең халык дөреслекне генә күтәрергә өйрәнгән дә бит. Әйдә, суз кулыңны. Бүген дөньяга чыктыгыз, тәки кабат кабинетыгызга кереп бикләнерсез.

Чокырдан чыгуы белән кресло иясе карашын кабат әллә кайлардагы ак болытка төбәп әйтә икән:

- Әптери ага, сез миңа ярдәм кулы суздыгызмы, әллә мин сезгәме? Суд белән өтәргә булыр иде дә, әйдә, чәнчелеп китсеннәр шунда, барыбер китәм моннан,- дип уйлап.
- Сез безгә ярдәм кулы суздыгыз, бугай, иптәш начальник.

Ниһаять, бездән китәр – котылырбыз, дип уйлый икән Әптери агабыз.

- Ә мин сездән китәм, ага, бу томана, аңсыз җирдә бер минут та тормыйм, -дип китү ягына борылган.
- Һай, алланың бирмеш көннәре дә бар икән, аңсызлыкны аңлап китә белгәч бик яхшы! Үзең әйткәндәй- сознательность!

  Әллә үзем ат белән калага илтим микән, хәер, замана башка – машина белән илтергә дә ун куллап килешерләр.Үзебездә менә дигән җир эшен белүчеләр юкмыни безнең?! Әнә, агрономыбыз – үзебезнең кеше ул! Шуны сайларбыз да.

  Күңелендә кайнаган шундый уйлар белән Әптери ага яңа силос базын ачарга китте. Әнә кояш та болытлардан арчылды, ахры.

Апрель 1969 ел.Чарджоу

## Солдат абыем.

Көн кояшлы. Шулай да җылы якларга хас булмаган салкын җил биткә бәрә.

Һәр солдат үз урынында. Шоферлар автопарк эчендә мәш киләләр , моторлар да һәрвакыт приказны үтәргә әзер дигән кебек гөрелдиләр.

Кинәт шәһәр урамнарында чыр-чу , көчле хәрәкәт башланды. Бу аңлашылмас хәлгә хәвефле мәгънә биреп , колак яргыч сигнал авазы һаваны ярып үтте.

- Тревога!

Вакытның искә алмас бер өлешендә бөтен часть тулы сугышчан хәзерлектә чыгу юлына тезелде.

Командир сүз башлаганда частьне әйләндереп алган кирпеч койма урыны-урыны белән җимерелә башлады. Солдатлар көтелмәгән хәлдән гаҗәпләнеп калдылар – шәһәр урамнары буйлап шашынган су ургыла иде. Командирның кыска приказы буенча частьта бөтен мөһим нәрсәне коткару эше башланды.

- Маршрут - офицерлар йорты! – диде часть командиры, ике шоферны аерып алып. – Коткарыгыз! Иң элек балаларны!

Шул арада , инде ярты метр күтәрелергә өлгергән суны чәчрәтеп, ике йөк машинасы шәһәргә ыргылды.

Безнең солдат шоферлар офицерлар йортына килеп туктаганда су метрдан артык күтәрелгән , куркыныч артканнан-арта иде. Машиналардан төшүгә бозлы-өшеткеч январь суы тәнне куырып алды. Җитезлек белән балаларны , хатын-кызларны кузовларга күчереп бетергәндә алар тирләп-пешеп беткәннәр иде. Шулай хәвеф-хәтәрсез генә берничә семья куркыныч булмаган урынга чыгарылды.

Берәүнең дә әйтүе кирәкми: солдатлар машиналарын йортлар янына туктаталар. Су һаман арта. Коткарырга , коткарырга! Солдатларның уе шул.

Тирә - юнь су, юлның кайда икәнен абайлап булмый. Зур тизлектә барганда беренче машина кинәт суга чумды, аның кабина түбәсе генә калкып тора. Арттан килүче солдат осталык белән тормозына басты, хәрби җитезлек белән иптәшенә ярдәмгә ашыкты. Чокырдагы бозлы суда бата-чума иптәшен чыгарды. Башы нык бәрелеп аңын югалткан иптәшен коткарылган хатын-кызлар янына куеп, машинасын кабат йортка борды. Аны туктатырга теләп дәшеп карадылар, ләкин совет солдаты йөрәгендә кабынган дәрт ялкынын ялвару сүзләре дә, һаман котырынган су ташкыны да баса алмады. Йорт янына килеп туктаганда су кабинага керә башлады , ә солдатның игътибары йортка төбәлгән, бу вакытта үзен бөтенләй оныткан, алдында торган бурыч белән генә яши иде ул хәзер.

Суга сикергәндә ачынып елаган нечкә , көчсез тавыш ишетелде. Бозлы су да калтыратмаган солдатны шушы хәлсез аваз дерелдәтеп җибәрде: “ бу бит бала тавышы!”

Бата-чума ул тавышка таба ашыкты. Бала елаган бүлмәнең ишеге бикле иде. Аны ватып, эчкә керде һәм елаудан ярсып беткән баланы күкрәгенә кысты. Солдат машинасы янына килгәндә су инде күкрәктән югары иде.

Бервакытта да карышмаган техникасы бу юлы аңа буйсынырга теләмәде. Кабыну системасы юешләнгән иде. Солдат, утыргыч астыннан плащ-палатка алып, баланы төрде дә суга сикерде. Шунда аның аяклары ниндидер каты әйбергә бәрелеп китте, авыртудан күз аллары караңгыланды, үзе дә сизмәстән чүгә башлады...

Суга төшүен күреп коты очкан баланың нәзек әче тавышыннан айнып киткән солдат, тешен кысып алга атлады. Аяк бүрәнәдәй авыр, үзәккә

төшеп сызлый. Күкрәктән бозлы суда һәр адымына ихтыяр көчен җыеп, баланы кулларында өскә күтәреп тоткан хәлдә атлады солдат.

- Нәнине коткарырга! Ничек тә егылмаска!

Менә ул чайкала-чайкала котткарылган хатын-кызлар янына якынлашты. .. Судан чыгып бер-ике адым атлауга ул сыгылып төште. Кечкенә кыз баланың : “Солдат абыем, тор инде”,- дигән ялвару сүзләре аның төшендә күргән кебек ишетелде.

Солдат госпитальдә аңына килде. Күзләрен ачуга ул медсестрадан :

- Су һаман артамы? – дип сорады.

Шулчак бүлмәгә, солдат коткарган кечкенә кызын җитәкләп, часть командиры килеп керде.

- Солдат абыем! – дип бала авыруның муенына сарылды һәм – әти, шушы солдат абый инде ул, - дип өстәде.

Күңелен биләгән шатлык хисләре егетнең йөзенә бәреп чыкты.

Полковник солдатның кулын кысты.

- Молодец! Үзеңне ничек хис итәсең?
- Яхшы, иптәш полковник, мине бүген үк частька кайтарыгыз...

Январь 1969 ел.

## Ык егете.

(Мөслим егете, минем якын дустым Салих Замилов истәлегенә)

...Иделем, гел сиңа ашкынам,
Җаныма ял бирә таң ату...

Йөрәгемә якын җыр ишетелгән ялгыз имәнгә юнәлдем. Мәгърүр карт имән дә күңелнең иң нечкә кылларына чиертеп уза торган җырның тәэсир көченә буйсынып, назлы-сагынычлы авазларга бирелеп утыра кебек тоелды миңа; мин дә җырның соңгы аһәңнәре яңгырап тынганчы җырчы егетне бүлмәдем. Аннан соң, кинәт айнып китеп, егет янына ук килдем.

- Син дә Иделдәнмени , егет?- дип сорадым мин. Ул иркенләп елмайды, бу вакытта аның иреннәре , йөзе генә түгел, ихлас беркатлылык, балаларча самимилек белән коңгырт күзләре дә елмаялар иде.
- Иделдән дисәм дә алдау булмый, барыбер аңа кушылабыз –Ыктан мин.

Аның шулай ярым шаярып җавап бирүе иркенләп сөйләшү өчен үзенчә бер кереш иде. Күптәнге дустым кебек тоелды ул миңа. Аның белән беррәттән яшел чирәмгә сузылдым.

- Сандугачлар көнләшерлек җырлыйсың, якташ!
- Кая инде – дип элеп алды ул,- шаулатабыз, каенны: җырчы югында түрдәге урында ,җырчы килгәндә идәндә; менә шундый җырчы без, ә теге көнләшә торган сандугачлар чыпчык нәселеннәндер ул...

Икебез дә көлешеп алдык.Ул бераз сүзсез торганнан соң горур аваз белән әйтеп куйды:

- Иделнең акчарлаклары да менә дигән җырчылар, ә уллары аның, уллары! Кем әйтмешли, агачыңны ат итеп яшәгәндә җырламыйча буламыни?!

... Бу ачык йөзле, көр күңелле, шаян телле Ык егете миңа бик ошады.Шушы көндә башланган танышлык Сарман якларында дүрт айдан артык уборкада йөреп, Төрекмәнстан чүлләренә чын хезмәткә килгәндә чын дуслыкка әверелеп өлгерде. Ык егете Салихның көннән-көн матур гадәтләре күренә барды һәм тугрылыгы, искиткеч гадилеге , көчле рухлы булуы белән ул һәр чиста күңелле солдат өчен дус була барды, үз чиратында безнең дуслык киңәя, ныгый килде.
Мине аның беркайчан да сиздереп борчыла, кайгыра белмәве , күңел төшенкелеге, үпкә, үч алу теләге дигән нәрсәләрне бөтенләй аңларга теләмәве, бигрәк тә һәрвакыт җор күңелле булуы сокландырды. Аның борчылуын җырлаган җырларында гына ишетә идем мин. Сагынуын да җыр белән суза иде ул. Өйдәгеләреннән хатлар озакласа , салмак тавыш белән онытылып “Әнием” җырын сузып җибәрә.

“Хат-хәбәрең юк бу араларда,
Сәлам әйтми искән җилләр дә...”,

-дип ешрак җырлап йөри башласа, синдә дә йөрәк бар икән, дип шаяртам. Ә ул бераз кызарынып ала да , кара,чынлап та бар бугай шул, дип куйган була.
Аның туры сүзлелеге, теләсә нинди очракта дөрес сүзне маңгайга бәреп әйтә белүе баштарак солдатлар арасында аңа карата тупас караш та тудыргалый иде. “Карантин” дигәнне үткәндә Салих белән булган бер хәлне сөйлисе килә.
Якшәмбе көнне Ленкомнатада газета-жулналлар дөньясына чумып утырабыз. Бүлмәгә һәммәбезгә дә таныш украин егете килеп керде. Солдатлар арасында “сачок” исеме алган бу гөмбәдәй капчык-юан егет строевой һәм физподготовкаларга йөрми. Ничектер медсправка юнәтеп алган һәм шул справка аны Салихча әйтсәк, “җил-яңгырдан” саклый иде.
Күмәк солдат тормышына ят, бер үзенчә йомылып яшәгән бу егетне күрүгә солдатлар нindидер аңлатып булмас канәгатьсезлек белдереп аңа кырын гына карап алдылар. Ә ул горур адымнар белән миңа таба килә башлады.

- Кара әле, - диде ул,- землякларың сине ВУЗ корбаны диләр, чыннан да шулаймы?
- Юк, мин үземне корбаннар рәтенә куярга җыенмыйм.
- О, да, да! –диде ул артисланып.-Син бит бары керә генә алмадың.
- Әйе, ләкин, кояш батмаган әле.
- Да-а-а ...,- дип сузды ул,- икебезгә дә бер үк язмыш туры килгән икән. Ә хәзер көймәләр комга терәлеп тора инде, җыйган белемнәр җилгә оча...

Ахры, артык түзеп утыра алмады Салих дус, кинәт кенә аңа таба борылды да чын ачу һәм зәһәре белән уклы сүзләрен тезеп китте:

- Сукыр тычкан син, иптәш, аңлашыламы? Сукыр тычканга хас язмышыңны кешенекенә бәйләмә. Бу-бер. Икенче, син саташасың, якташның көймәсе комга терәлмәгән, монда берәүнең дә алай

терәлмәгән әле. Син әзрәк күзеңне ач, шунда бары тик бер үзеңнең генә көймәң комга терәлгәнен күрерсең. Өченчедән.... өченчедән беләсеңме нәрсә, җилдән җыйган белемнәрең җилгә очуына шик юк. Аңлашыламы?

Мин ни дияргә дә белмим, дустымның болай кинәт итеп бәрелүе миңа ошап бетмәсә дә, аның тулаем дөреслеге минем телемне бәйләде. Ә комга терәлгән егетебез нахакка кыйналган кеше кебек ашардай булып Салихка төбәлгән, тик ул да бер сүз дә әйтә алмый. Дөрес сүзгә җавап юк дип тиккә әйтмиләрдер. Әйе, мондый күренешләр Салих дус белән байтак кына булгалады.

Безне авторотага күчерделәр һәм шул көннән башлап мин егетне үз янымда сирәк күрә башладым. Кайчан карама ул автопаркта, “старослужащий” солдатлар аны үз һәм тиң күрәләр,әйтерсең, Салих белән алар арасында инде күптәнге дуслык урнашкан.

Авторотага күчүгә унбиш-егерме көн дә үтмәде, яшь солдатлар арасында иң беренче итеп Салих Замиловны җиңел машинага утырттылар. Зенитно-ракетный частьнең хәрби үзәгенә илебезнең көньяк күге сагында сменалап постта торучы оперативный бүлек офицерларын йөртүне дустым Салихка тапшыру һәркайсыбыз өчен бик табигый иде, чөнки бу вакытта Салихтан башка берәүне бу хезмәттә күз алдына китерү дә кыен иде.

Чын солдат тормышының тулы сулышы белән яшәргә, көрәшергә өйрәнәбез; уңышлар да күренә бара. Ни дисәң дә, армия сафында ярты елдан артык вакыт үткән.

Дустым Салихның тынгысыз омтылышы, көчле энергиясе һәм олы тырышлыгы да яшь солдатлар семьясында иртәрәк күренде. Хезмәтенә ярты елдан артканда ул инде “Отличник боевой и политической подготовки” булып күтәрелде. Әлбәттә, тыныч чорда Совет Армиясе сафларында солдатның сөйгән Ватанына беренче иң зур бүләге, халкы ышандырган изге постка лаеклы булуын эше белән раслауда беренче адым, алга таба өметләр тулы башлангыч иде бу.

1968 елның җәендә тугандаш республикабыз Чехословакиядә Ленин юлындагы һәр кешенең күңелен яралаучы болганулар башланды. Кешелекнең тынычлыгын качыра торган һәрбер дөньякүләм буталыш хәрби частьлар өчен дәвамлы учениеләрсез узмый. Бу бөтенсоюз күләмендәге хәрби өйрәнүләрдә күп кенә солдатлар осталыкларын, ныклы белемнәрен, өлгерлек һәм үзләре идарә итә торган хәрби техниканы яхшы белеп, аның белән зур төгәллектә эш итә алуларын күрсәттеләр. Дивизия командованиесе күп кенә солдатларга приказ тәртибендә рәхмәт игълан итте. Алар арасында дустыбыз Салих Замиловның да булуы һәркайсыбыз өчен табигый күренеш кебек тоелды.

Һәр адымын мең кат исәпләп атлый кебек тоела иде миңа Салих, чөнки, ул һәрвакыт машинасы белән готовностьта тора. Һәм аның частьтан чыгып китү вакыты да нибары 2 минут кына иде. Готовностьлар никадәр еш булса да, төннең-көннең теләсә кайсы вакытында теләсә нинди эшеннән аерылып часть капкасыннан чыгып “оча” торган егетебез үз хезмәтеннән бер генә

тапкыр да зарлануын ишеткәнем булмады. Киресенчә, һәрвакыт көләч, шат күңелле йөрәге бетмәс-төкәнмәс могҗизалы дәрт һәм ялкын белән тулы иде кебек. Мин аңа хөрмәт белән карап, шулкадәр җаваплы хезмәтеннән никадәр шатлык алып яши, олы җаваплылык чиксез дәрт кенә өсти, ахры, моңа, дип куя идем.

Тугыз ай дәвамында төгәллек һәм тиңсез өлгерлек күрсәтеп, беркайчан да сынатмыйча ике минутлык хәрби хәзерлектә тора алуы, моның белән бөтен часть идарәсен хәрби хәзерлектә дип таныткannары өчен Ык егете Салих Замиловны туганнарына "Мактау хаты" белән бүләкләделәр. "Туган җиргә мактау хаты, эшләгән урынга мактау хаты белән часть командованиесенең бүләкләве, ул – улыгыз иленә лаек солдат, шундый тәрбия белән Ватанга чын кешеләр бирүегез өчен рәхмәт, дип яңгырый."

- Олы бүләк бу, дускай, сынатмыйбыз бит!- дип мин аңа үземнең сөенечемне белдердем. Ул, гадәтенчә, шундук элеп алды, җилкәгә дусларча каккалап алды да елмаеп кына:
- Без Иделнекеләрме?! Әйе, без Идел балалары ! Иделнең акчарлагы да давылга каршы күкрәк киереп оча! – диде ул.

Чыннан да, хезмәтендә ул кыю акчарлак кебек һаман саен үсеш юлында иде. Күпне белергә омтылыш, гаять зур кызыксынучанлык, вакытны файдага төгәл бүлә, файдалана алу хезмәтенә ел тулганда егетебезне Совет Армиясе отличнигы дәрәҗәсенә күтәрде. Ләкин ирешкәне белән генә тынычланып кала торганнардан түгел иде ул. Хезмәтенә ике ел тулганда Салих Замилов хәрби үзәккә үзе йөртә торган офицерларның эшләре белән тирәннән кызыксына, үзе кертелә торганнарын җентекләп өйрәнергә кереште. Кайдандыр китапларын тапты, болай да аз вакытын шуларны өйрәнүгә дә бүлә белде.

Ә ике-өч ай үтүгә Салих миңа бик сөенеп иртәнге сәгатьтә бер старший лейтенант урынында ярты сәгать эшләп каравын, эшли алуын сөйләде.

Солдатларга төрле яклап булышу, алар белән чын күңелдән гапләшү , кайнар сүз көрәштерүләрдә Салих дусны узучы юк иде. Шуңамы икән, әллә машинаны бик яхшы белгәнгә, һәрвакыт бик теләп булышкангамы, һәммәбез дә аны "безнең мастер" дип йөри идек.

Хезмәткә ике ел тулып китте. Приказ буенча безнең бик азларыбызны гына демобилизовать итәргә тиешләр иде. Срогы тулды дип исәпләнгән һәрбер солдат, нәрсә уйларга да белмәгән хәлдә, нидер көтә иде. Сроклары тулган шофер солдатларны группалап-группалап СССРның төрле почмакларына икмәк ташырга җибәрделәр. Салих белән мине дә "легковиклар" дип, урып-җыюга китүчеләр исемлегенә кертмәгәннәр. Минем йөрергә теләгем булмады, ә Салих дус, китәм булгач китәм, дигән фикер белән йөри башлады.

Әлбәттә, иң җаваплы хезмәттә бер генә дә сынатмыйча ике ел тора белгән, үз хезмәтенең үзенчәлекләрен биш бармагыдай белгән солдатны, хәрби идарәнең җибәрәсе килмәде, ничек кирәк алай соңгы партиянең частьтән китү-китмәү мәсьәләсен сузып, калдырасылары килде. Тик егетебез мәми авызлардан түгел иде шул. Оперативный бүлек офицерлары аша үз теләгенә ирешә алды ул.

Ә китәргә хәл ителгәнлеген ул үзе китү сәгатьләрендә генә әйтте.

- Менә, кайнеш, тәки китәм бит. Штаб начальнигы үзе язган мине списокка.

Ул бик сөенә һәм кабалана-кабалана сөйләшә иде, мин:

- Дембельгә нибары 3-4 ай калды, нигә әллә кая ашкынасың, дустым,- дип әйттем. Иң якын хезмәттәш дустымнан аерыласы килми иде.

Ул көр күңел белән:

- Ашкынып яшәмәгәч дөньяда яшәүнең мәгънәсе юк, кайнеш!- диде дә, кабат җилкәгә кага-кага дулкынланып әйтте,- иген басулары, икмәк исе, авыл моңнары тарта, кайнеш! Мин бит чәчеп, тырмалап, игеп, тугайларда тайлар көтеп үскән кеше. Иген кырларына чыгып башаклар җырын тыңлавы никадәр олы бәхет дөньяда! Менә ишеткәнең бармы “Идел кызы”н.

Мин бер сүз дә әйтә әйтә алмый калдым, ул җырлап та җибәрде:

Дулкын-дулкын арыш тибрәлгәндә
Шаулап үтәм иген кырларын.
Эш сөюче якташларым җырлап
Нечкәртәләр күңел кылларын.

Җыр безнең күңелләрне ерак Татарстаныбызга очырды, һәр икебез дә үткән матур көннәрнең хатирәләрен күңел дәфтәребездә актарабыз.

Ул ара автобус та килеп җитте. Салих белән кысып кочыштык та кулларны кысыштык:

- Я, кайнеш, син дә Иделгә кушыласың, мин дә иделгә кушылам, димәк, штатскийлар булып очрашырбыз!
- Хуш, дустым! Иделдә очрашуга кадәр.

Ләкин, тормыш үзенекен итте, Салих дустым шушы китүеннән частька да, туган ягы Ыкка да үз аяклары, кайнар йөрәге, шат йөзе белән кайтып кертә алмады.

Август 1969 ел.